РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАРЫ**

2020 елның «20» октябре 419 №

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы «Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү чаралары турында»гы 190 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы Күрсәтмәсенә таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы «Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү чаралары турында»гы 190 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктта:

а) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) арендаторлар мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне дәвамында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестрындагы коммерциясез оешмалар белән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен дә) арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда аренда түләүләрен кичектерүне күз алдында тотучы өстәмә килешүләр төзү:

аренда түләве буенча бурыч арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокт, 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр күләмендә, айга бер тапкырдан да еш алынмыйча түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә аренда түләве буенча бурыч берьюлы түләнә;»;

- б) пунктчасында «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары» сүзләреннән соң, «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар» сүзләрен өстәргә;

- 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага кадәр муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре (шул исәптән җир кишәрлекләре) аренда түләве буенча үтәлмәгән бурычы булмаган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестрындагы коммерциясез оешмаларга аренда түләвен кичектереп түләү бирелә дип билгеләргә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов